СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2022 г. Агрыз № 24-5

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы Регламенты турында» 08.12.2005 елның 3-2 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 8 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясындагы 7 өлеше нигезендә, муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, туры килмәүләрне бетерү һәм аны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. "Муниципаль район Советы Регламенты турында " 08.12.2005 елның 3-2 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.01.2022 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
08.12.2005 елның 3-2 номерлы карары белән
расланды
(карар редакциясендә
29.12. 2022 №24-5)

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Муниципаль район Советы Регламенты турында» 08.12.2005 № 3-2 карарына үзгәрешләр кертү**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 08.12.2005 елның 3-2 номерлы карары белән расланган муниципаль район Советы регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Регламентның 67 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**67 нче статья**

1. Әгерҗе муниципаль районы башлыгы Әгерҗе муниципаль районы Советы депутатларына конкурс нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынына кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссиясе тарафыннан кертелгән кандидатураларны тәкъдим итә.

Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен сайлау, Әгерҗе муниципаль районы Советы тарафыннан башка карар кабул ителмәсә, ачык тавыш бирү юлы белән кандидатура буенча фикер алышудан соң үткәрелә. Ачык тавыш бирү белән үткәрелә.

2. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен сайлаганда катнашучы Әгерҗе муниципаль районы Советы депутатларының билгеләнгән саныннан 1/2 өлеше тавыш бирсә, кандидат сайланган дип санала.

3. Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе сайланганнан соң Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен башкарырга керешә.

4. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең вәкаләтләре Әгерҗе муниципаль районы башлыгы белән төзелгән контракт нигезендә билгеләнә.»